ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№_1_ от «__10_»___01_____2018 г.

2018 елга Мамадыш муниципаль районында
балаларга сәнгать – эстетика юнәлешендә
өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә
белем бирү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының сәнгать – эстетика юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив буенча финанслауны кертү турында” 2014 елның 14 декабрендәге 854 нче санлы карары, Мамадыш муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. 2018 елга расларга:

Мамадыш муниципаль районының сәнгать-эстетика юнәлешендәге балаларга -өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны, 1 №лы кушымтада каралганча;

- сәнгать-эстетика юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга төзәтмә кертү коэффициентын 0,5 күләмендә.

2. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының финанс- бюджет палатасына сәнгать-эстетика юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны әлеге карарның 1 пуктына туры китереп тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы И.М. Дәрҗеманов